ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 422 от «07» 12 2022 г.

Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 07 октябрендәге «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Мамадыш муниципаль районы хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1187 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль учреждениеләр хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасын раслау турында» 2017 ел, 14 август, 569 нчы карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль учреждениеләр хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасына үзгәреш кертү хакында» 2022 елның 19 августындагы 865 нче һәм 2022 елның 15 сентябрендәге 1007 карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 07 октябрендәге «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Мамадыш муниципаль районы хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү

0000011501

шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 1187 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Мамадыш муниципаль районы хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәнең II бүлегендә, «хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары» 1 нче таблицаны түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

1 нчеТаблица

| № п/п | Хезмәткәрләрнең вазифалары | Вазифаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Учреждение җитәкчесе | 19862,00 |
| 2 | Оператив кизү торучы | 15279,00 |

1.2. Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Мамадыш муниципаль районы хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәнең III бүлегенең 6 пунктын үз көчен югалтты дип танырга.

1.3. Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Мамадыш муниципаль районы хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәнең III бүлегенең «Дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматлар белән эшләү, аларның серен яшерү һәм тарату, шулай ук шифрлар белән эшләү өчен өстәмәләр» 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Даими нигездә дәүләт серенә кертелгән гражданнарга һәм дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» 2006 елның 18 сентябрендәге 573 номерлы һәм «Россия Федерациясендә шифр хезмәте хезмәткәрләрен социаль яклау турында» 1997 елның 27 декабрендәге 1639 номерлы карарлары нигезендә, даими нигездә дәүләт серенә кертелгән хезмәткәрләргә, кзаконнарда билгеләнгән тәртиптә рөхсәт алу шарты белән, дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен елына вазыйфаи окладның 2,5%ы күләмендә айлык процент өстәмәсе түләнә.

2. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче О.Н.Павлов